| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 31 нче октябре Олы Кайбыч авылы № 23

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 нче октябрендәге 22 нче номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында»гы 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 нче октябрендәге 22 нче номерлы «Җир салымы турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче маддәнең 2 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)»;

1.2. 3 нче маддәдә:

а) исемендә «һәм сроклар» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 нче маддәнең 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым чоры йомгаклары буенча бюджетка түләнергә тиешле салым суммасы салым түләүчеләр - оешмалар тарафыннан Россия Федерациясе салым кодексының 396 маддәсендәге 1 нче пункты нигезендә исәпләнгән салым суммасы һәм салым буенча аванс түләүләренең салым чоры дәвамында түләнергә тиешле суммалар арасындагы аерма буларак билгеләнә.

Хисап чоры квартал буларак билгеләнгән салым түләүчеләр агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталы узгач, аванс түләүләре суммасын җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлеше буенча салым ставкасының бер чирегә буларак исәпли.»;

в) 3 нче маддәнең 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым түләүче оешмалар тарафыннан узган салым чорыннан соң килә торган елның 1 мартыннан да соңга калмыйча салым түләнергә тиеш. Салым буенча аванс түләүләре салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан узган хисап чорыннан соң килә торган айның соңгы көненнән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.»;

2. Гамәлдән чыккан дип санарга:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2008 елның 06 нчы июлендәге 10 нчы номерлы «Җир салымы турында»гы карарын;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2009 елның 17 нче ноябрендәге 28 нче номерлы «Җир салымы турында»гы карарын;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2010 елның 03 нче ноябрендәге 6 нчы номерлы «Җир салымы турында»гы карарын;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 нче октябрендәге 32 нче номерлы «Җир салымы турында»гы карарын (2012 елның 12 нче октябрендәге 32 нче номерлы үзгәрешләр белән).

3. Әлеге карарның 1.1 пункты, 1.2 пунктының «б» пунктчасы 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

4. Әлеге карарның 1 өлешендәге 1.2 пунктының «а», «в» пунктчасы 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин әлеге карарның рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк түгел.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча http://bkaybic-kaybici.tatarstan.ru, Олы Кайбыч авыл җирлеге мәгълүматый стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл җирлеге Башлыгы А.И. Рәхмәтуллин